КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 30 декабрь г.Казань № 1488

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашыру буенча чаралар турында» 2022 ел, 23 март, 258 нче карары белән расланган 2022 елда Татарстан Республикасының хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашырганда Татарстан Республикасының барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондының бюджет ассигнованиеләре торган Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашыру буенча чаралар турында» 2022 ел, 23 март, 258 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 17 август, 846 нчы, 2022 ел, 14 сентябрь, 1001 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган 2022 елда Татарстан Республикасының хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашырганда Татарстан Республикасының барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен

финанслашу максатларында федераль бюджеттан финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондының бюджет ассигнованиеләре торган Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

2.6 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 09 август, 553 нче карары белән расланган «2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» дәүләт программасының тиешле күрсәткечләренә ирешү өчен билгеләнгән субсидия күләме, анның максатчан билгеләнеше, субсидия бирү нәтиҗәләренең төгәл төгәлләнү датасы һәм ахыргы мәгънәсе (нәтиҗәләрнең төгәл санлы сыйфатламасы)»;

өченче абзацта «һәм субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләр» сүзләрен төшереп калдырырга.

3.1 пунктның икенче абзацында «һәм субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Субсидия бирүнең планлаштырылган нәтиҗәләре:

Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чаралар кысаларында эшсез гражданнарның җәмәгать эшләренә 2022 елның 21 декабренә кадәр эшкә урнаштырылган халык саны;

Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чаралар кысаларында эштән азат ителү куркынычы яный торган хезмәткәрләр арасыннан 2022 елның 21 декабренә кадәр эшкә урнаштырылган хезмәткәрләр саны.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин